СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Карар**
19.02.2020 ел

**Решение**
№ 3-53

Шәдче авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 11 апрелендәге 1-32 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә инвалидларнысоциаль яклау турында»Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»һәм«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләркүрсәтүне оештыру турында»Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктынүз көчен югалткан дип тану хакында» 2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон,«Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законынигезендә,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Шәдче авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-32 номерлы карары (2018 елның 17 сентябрендәге 2-37 номерлы редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенТөзекләндерү кагыйдәләренәтүбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29.Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шул исәптән социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, җәмәгать һәм җитештерүбиналары, төзелеш һәм корылмалар, шул исәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашканурыннарны да кертеп), ял урыннарында, I, II төркеминвалидлары идарә иткән транспорт чараларын һәм мондыйинвалидларны һәм (яки) инвалид балаларныйөртүче транспорт чараларын түләүсез кую өченкимендә 10 процент урын (әмма берурыннан да ким түгел) бүлеп бирелә.III төркеминвалидлары арасыннан булган гражданнарга әлеге өлешнормалары Россия Федерациясе

Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тарала.Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» танып-белү билгесе куелырга һәм бу транспорт чаралары турында мәгълүмат инвалидларның Федераль реестрына кертелгән булырга тиеш.»

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлегенеңмахсусмәгълүматистендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, "Интернет" мәгълүмати-коммуникациончелтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / В.В.Шрыков/